МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2019 г.Казань № 1021

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 9 декабрендә 5975 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән (әлеге боерык редакциясендә) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 1.2 пункындагы 2020 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керәчәк бишенче һәм алтынчы абзацлардан кала рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә, дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 14 ноябрендәге 1021 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 № 821, 07.06.2016 № 317, 20.07.2016 № 420, 28.11.2016 № 668, 27.02.2017 № 104, 08.06.2017 № 349, 28.05.2018 № 401, 18.09.2018 № 857, 04.02.2019 № 77, 07.05.2019 № 322, 10.09.2019 № 689 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктта:

беренче абзацта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәте алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «җинаять-үтәтү системасы органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацта «җинаять-үтәтү системасы органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

беренче пунктчада «2.8, 2.10, 2.11» саннарын «2.7, 2.9, 2.11» саннарына алмаштырырга;

1.6 пуктның унынчы абзацында «(алга таба – 601 номерлы указ)» сүзләрен «(алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).«;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтү өчен түләүгә субсидия-ташлама (алга таба субсидия-ташлама) билгеләү | 5 номерлы федераль законның 14 ст. 1 пунктындагы 8 пунктчасы, 15 ст. 1 пунктындагы 5 пунктчасы, 16 ст. 1 пунктындагы 5 пунктчасы, 18 ст. 2 пунктындагы 2 пунктчасы, 21 ст. 1 пунктындагы 9 пунктчасы;<br>122-ФЗ номерлы федераль законның 154 ст. 8 пункты;<br>181-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясы; 175-ФЗ номерлы федераль закон;<br>1244-1 номерлы РФ Законының 14 ст. 3 п.;<br>2123-1 номерлы карарның 1 п.;<br>2-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 17 п.;<br>63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>542 номерлы ТР МК |

| | | |
|---|---|---|
| | | карарының 2 п.;<br>192 номерлы ТР МК карары |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | 126 номерлы нигезләмәнең 2.2 п.;<br>251 номерлы тәртипнең 4 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | 126 номерлы нигезләмәнең 2.2 п.;<br>251 номерлы тәртипнең 4 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гарызнамә җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша сорату зарурлыгы булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү чоры ун көнгә кадәр озайтыла.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Карарны бирү субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | 126 номерлы нигезләмәнең 2.2 п.;<br>251 номерлы тәртипнең 8 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт | 1. Субсидия-ташлама бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы | 126 номерлы нигезләмәнең 2.2 п.;<br>251 номерлы Тәртипнең 5 |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Регламентка карата 1 нче кушымтада китерелде.<br>1.1. Күпфатирлы йортларда торак урыннарның милекчеләре өстәмә рәвештә аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.<br>2. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32 пунктчасында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә гариза тапшырган айдан алда килгән алты ай өчен гариза бирүче тарафыннан алынган керемнәр турында документларны тапшыра (Россия Федерациясе Пенсия фондында алар турында белешмәләр булган түләүләрдән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы, Россия Оборона министрлыгы түли торган түләүләрдән тыш), шул исәптән:<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында»;<br>хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы турында;<br>дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация турында;<br>эштән куылганда түләнә торган | пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы турында;<br>Россия Федерациясенең граждани законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү турында;<br>эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында;<br>барлык дәрәҗәдә бюджетлардан социаль түләүләр турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, кушып түләүләр) турында;<br>пенсионерларны өстәмә ай саен матди тәэмин итү турында;<br>ихтыяри иминиятләштерү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр турында, дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп;<br>отставкага киткән судьяларга ай саен түләнә торган гомерлек тәэминат турында;<br>оешмалар белән найм шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы, бала карау буенча отпускта булган гражданнарга ай саен түләнә торган компенсация түләүләре турында.<br>3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | затлар өстәмә рәвештә эш урыныннан субсидия-ташлама алу хокукы турында белешмә дә тапшыра.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ, банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын, шулай ук, гамәлдәге законнарда каралган очракларда, гариза бирүченең субсидия-ташлама алу хокукын раслаучы документны күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:<br>Россия Федерациясе Пенсия фондыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләрнең, компенсация түләүләре һәм пенсионерларны өстәмә ай саен матди тәэмин итү түләүләренең күләмнәре турында (субсидия-ташламаны ялгыз яшәүче пенсионерларга, хезмәт ветераннарына, Татарстан | 126 номерлы нигезләмәнең 2.1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга, авыл җирлегендә эшләгән һәм яшәүче белгечләр исәбендәге пенсионерларга билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына түләнгән түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр суммасы турында (субсидия-ташламаны хезмәт ветераннарына билгеләү өчен) (вәкаләтле органда);<br>федераль законнар нигезендә ай саен бирелә торган акчалата түләү алудан баш тарту турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан (алга таба – Россия ЭЭМ) түләнә торган пенсия күләме турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия ЭЭМда);<br>Россия Оборона министрлыгыннан (алга таба – Россия Оборона министрлыгы) түләнә торган пенсия күләме турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Оборона министрлыгында);<br>җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (субсидия-ташламаны хезмәт ветераннарына билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булу буенча пособиеләр турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);<br>эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре һәм эшсезләргә булган башка түләүләр (түләүләрнең булмавы) турында белешмәләр (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен (Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесендә (алга таба – мәшгульлек үзәге));<br>тууны дәүләт теркәвенә алу турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (вәкаләтле органнарда);<br>ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (җирле үзидарә органнарында);<br>өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (вәкаләтле органнарда); | |

| | | |
|---|---|---|
| | аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (вәкаләтле органнарда);<br>инвалидка (инвалид балага) айлык акчалата түләү билгеләү турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә (алга таба – Росреестр));<br>әгәр гариза бирүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>гражданинның 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына | |

| | | |
|---|---|---|
| | туры килүе турында мәгълүматлар (гражданинның 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондында).<br>Гариза бирүче Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр полрталы аша мөрәҗәгать иткәндә өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:<br>гариза бирүченең паспорты чын булуын раслау турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында);<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 | |

| | | |
|---|---|---|
| | пунктында билгеләнде.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>3. Гариза бирүченең үзе яшәгән урынга карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32 - 40 пунктчаларында күрсәтелгән затларның Татарстан Республикасы законнарында яисә федераль законнарда билгеләнгән башка нигезләр буенча, 63-ТРЗ номерлы законның 9 статьясы һәм 251 номерлы тәртипнең 15 пункты таләпләрен исәпкә алып, социаль ярдәм чараларын алуы;<br>субсидия-ташлама алу өчен төгәл булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылуы; | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен | Дәүләт хезмәте түләүсез | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтөн һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә | Кирәкле барлык документлары белән гариза килгән көнне<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә. | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 п.,<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керәп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алу мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләренең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны: дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча); дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша, шул исәптән электрон почта буенча, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматларыннан җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнешкә кереп эш итү таләп ителми. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексны мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза бирүчеләрнең түбәндәге категорияләре гариза җибәрә ала:<br>Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсе аша айлык акчалата түләү алучы | 126 номерлы нигезләмәнең 2.2 п.;<br>63-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 11 п.;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ ст.»; |

| | | |
|---|---|---|
| | инвалидлар;<br>граждан хәле (инвалид бала туу, өйләнешү, аерылышу) актларын Татарстан Республикасында теркәү һәм инвалид бала белән бергә яшәү шарты белән Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Пенсия фонды бүлекчәсе аша ай саен акчалата түләү алучы инвалид баланың ата-анасы;<br>инвалид бала тууны теркәү Татарстан Республикасында башкарылган очракта, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге аша ай саен акчалата түләү алучы инвалид балаларны опекунлыкка алучылар.<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе электрон формада бирелә. | |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.1 пунктның бишенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.5.1 пунктның өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хатаны төзәтү.

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны

(андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)» сүзләрен «(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклый торган затның вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)»;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләрен «Гариза бирүченең яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклаучы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге»

дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 31.10.2016 № 612, 08.06.2017 № 349, 01.06.2018 № 426, 18.09.2018 № 860, 23.04.2019 № 297 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.5.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр)

һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.5.2 пунктта:

беренче пунктчада «2.8, 2.10, 2.11» саннарын «2.7, 2.9, 2.11» саннарына алмаштырырга;

1.6 пунктның җиденче абзацында «(алга таба – 601 номерлы указ)» сүзләрен «(алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).«;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтү өчен түләүгә субсидия (алга таба – субсидия) билгеләү | РФ Торак кодексының 159 ст. 1 п.;<br>665 номерлы нигезләмәнең 1.2 п. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | 665 номерлы нигезләмәнең 1.3 п. |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар | 761 номерлы кагыйдәләрнең 7 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге | Субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар алынган көннән башлап ун эш көне эчендә кабул ителә.<br>Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны электрон рәвештә | 761 номерлы кагыйдәләрнең 42 пункты<br><br>761 номерлы кагыйдәләрнең 13(2) |

| | | |
|---|---|---|
| каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | тапшырмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган барлык документларны электрон рәвештә тапшырганчы, ләкин барлык документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителгән көннән башлап бер айдан да артмаган вакытка туктатыла.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә бирү | пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Барлык гаилә әгъзаларын һәм туганлык дәрәҗәсен күрсәтеп, гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.<br>2. Гариза бирүченең аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынга хуҗа булуының һәм аннан файдалануының хокукый нигезләрен раслаган документларның күчермәләре, андыйларга түбәндәге документларның берсе карый:<br>а) хосусый торак фондында найм шартнамәсе буенча торак урын яллаучыга – торак урынның найм шартнамәсе;<br>б) торак урынга (фатирга, торак йортка, фатирның яки торак йортның бер өлешенә) хокуклары Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуның бердәм реестрында теркәлмәгән милекче өчен: | 761 номерлы кагыйдәләрнең 8 п.; методик рекомендацияләрнең IV өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | торак яки торак-төзелеш кооперативыннан кооператив әгъзасы булып торган гариза бирүченең кооперативтан әлеге затка тапшырылган фатирга пай кертеменең тулысынча түләнгән булуы турында кооперативның вәкаләтле идарә органыннан аның уставта билгеләнгән компетенциясе нигезендә бирелгән белешмә;<br>«Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында» федераль закон үз көченә кергән вакытка кадәр торак урынга милекчелек хокукы барлыкка килүен раслаучы документ;<br>торак урынга милекчелек хокукына карата законлы көченә кергән суд акты (суд карары яки суд билгеләмәсе);<br>закон яки васыять буенча мирас хокукы турында таныклык;<br>в) торак яки торак-төзелеш кооперативына карый торган торак урында яшәгән очракта, – торак яки торак-төзелеш кооперативыннан анда гариза бирүченең әгъза булып торуы турында кооперативның вәкаләтле идарә органыннан аның уставы нигезендәге компетенциясенә туры китереп бирелгән белешмә.<br>3. Гариза бирүченең һәм барлык гаилә әгъзаларының субсидия бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрен раслаучы документларның күчермәләре, аларга түбәндәгеләр керә:<br>төп эш урыныннан һәм барлык | |

өстәмә эш урыннарыннан керемнәр турында белешмәләр;
Россия Федерациясе Пенсия фондыннан һәм Россия ЭЭМ, Россия Оборона министрлыгыннан гамәлгә ашырыла торган түләүләрдән тыш, барлык дәрәҗә бюджетларыннан, дәүләтнең бюджетка карамаган фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр күләме турында белешмәләр;
милекчелек хокукында гариза бирүченеке һәм аның гаилә әгъзаларыныкы булган мөлкәттән керемнәр күләме турында белешмәләрне үз эченә алган документлар (гариза, шартнамә күчермәсе һ.б.);
предметы эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган граждани-хокукый шартнамәләр;
шартнамәләр һәм торак урыннарны поднаемга тапшырудан алынган керемнәр турында белешмәләре булган башка документлар;
салым органы документы белән таныклана торган шәхси эшкуарлар сайлаган салым салу системасына карап, Россия Федерациясенең салым законнарында каралган документлар;
опекада (попечениедә) торган затларны караган өчен опекунга (попечительгә) түләнә торган акчалар күләмен раслаучы документлар;
гражданнарның мөстәкыйль декларацияләнгән керемнәре турында гаризалар, керемнәрне

| | | |
|---|---|---|
| | документаль раслау мөмкинлеге булмаганда һәм фактта алынган керемнәр документта күрсәтелгәннән зуррак булган очракта, хезмәт һәм шәхси эшкуарлык эшчәнлегеннән ирекле формада рәсмиләштерелгән керемнәрдән тыш;<br>шәхси эшкуарның кәгазьдә керемнәрне һәм чыгымнарны һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсе, – салымнар һәм җыемнар билгеләүнең гомуми шартлары һәм салым салуның гадиләштерелгән системасы кулланылганда:<br>шәхси эшкуарның кәгазьдә керемнәрне һәм чыгымнарны һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсе һәм хисап чорындагы чыгымнарны раслаучы беренчел исәпкә алу документлары, – әгәр салым салу объекты булып чыгымнар зурлыгына киметелмәгән керемнәр торса;<br>салым органнары раслаган салым декларациясенең күчермәләре, – эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан йөкләнгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын кулланганда; шәхси эшмәкәрнең керемнәрен һәм чыгымнарын һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсе һәм хисап чоры чыгымнарын раслый торган беренчел исәпкә алу документлары, – салым салу объекты чыгымнар күләменә кимемәгән керемнәр булган очракта;<br>салым органнарында таныкланган | |

| | | |
|---|---|---|
| | салым декларациясе күчермәләре, – эшчәнлекнең аерым төрләре өчен кулланылган керемнәргә бердәм салым рәвешендәге салым салу системасын кулланганда.<br>4. Түбәндәгеләрне таныклаучы документларның күчермәләре:<br>гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе гражданлыгына каравын (аталган документлар ведомствоара гарызнамә гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булган очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына);<br>гариза бирүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе белән торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә чит ил гражданнарына субсидияләр бирүне рөхсәт итә торган халыкара шартнамәсе төзелгән дәүләт гражданлыгына каравын.<br>Гариза бирүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында керемнәр булмаган очракта, гариза бирүче өстәмә рәвештә гражданнарның керемнәре булмавын раслаучы документларның күчермәләрен тапшыра, аларга түбәндәгеләр кирә:<br>а) 23 яшькәчә булган, урта һөнәри белем бирүнең һәм югары белем бирүнең төп мәгариф программалары буенча белем бирү оешмаларында көндезге формада укучы гражданнар өчен, – стипендия булмавы турында белешмә;<br>б) эшкә урнашмаган гражданнар өчен, – эштән китү турында соңгы язуы булган хезмәт кенәгәләре | |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәләре;<br>в) гражданнарның эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган яки чикләнгән затлар категорияләренә каравын раслаучы документ, аларга түбәндәгеләр керә:<br>беренчел тикшерү һәм суд тикшерүе чорында сак астында тотылучы затлар;<br>дәвамлы стационар дәвалавында булган затлар (шундый дәвалау чорына);<br>билгеләнгән тәртиптә билгесез югалган яки үлгән дип игълан ителгән чорына кадәр эзләтүдә булган затлар;<br>3 яшенә җиткәнчегә кадәр бала караучы, 1,5 яшенә җиткәнче баланы карау буенча отпуск чорында ай саен түләнә торган пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган һәм 3 яшенә кадәр бала карау буенча отпускта торучы гражданнарга ай саен түләнә торган компенсация түләвен алмаучы аналар.<br>Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Гариза бирүче аның белән бергә даими яшәү урыны буенча яшәгән затларны аның гаилә әгъзалары итеп тану турында суд карары актын тапшырырга хокуклы, – гариза бирүче белән даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәгән затлар арасында бер гаиләнеке булу мәсьәләсендә аңлашылмаучанлыклар булган | |

| | | |
|---|---|---|
| | очракта.<br>Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга яисә заказлы почта юлламасы итеп кулга тапшыру турында белдерү белән җибәрелергә мөмкин.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый | Ведомствоара хезмәттәшлек итү | 761 номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:<br>торак урынга (фатирга, торак йортка, фатирның яки торак йортның бер өлешенә) милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында (Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә);<br>балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);<br>гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);<br>гаилә таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);<br>балага опека билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);<br>баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарында);<br>дәүләтнең яки муниципаль торак фондындагы торак урыннан файдалануның хокукый нигезләре булуы турында (вәкаләтлә органнарда);<br>гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (вәкаләтле органнарда);<br>эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, | кагыйдәләрнең 8(1) пункты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләү, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләү турында (халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте учреждениеләрендә) (алга таба – мәшгульлек үзәкләре);<br>торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр турында, торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә бурыч булуы (юклыгы) турында (идарәче компанияләрдә);<br>торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чаралары сыйфатында алына торган түләүләрнең күләме турында (социаль яклау органнарында);<br>пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә ай саен түләнә торган матди тәэминатларның күләмнәре турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Россия ЭЭМ тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында);<br>Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Оборона министрлыгында);<br>җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри | |

| | | |
|---|---|---|
| | авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында);<br>социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләме турында (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләме турында (социаль яклау органнарында яки | |

| | | |
|---|---|---|
| | Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләме турында (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында).<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала | |

| | | |
|---|---|---|
| | торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте | 1. Әлеге Регламентның 2.5 | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>3. Гариза бирүченең үзе яшәгән урын буенча мөрәҗәгать итмәве.<br>4. Күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору нигезләре:<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гаризаны һәм документларның күчермәләрен 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты – әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшырганчыга кадәр, ләкин төп документларны яки аларның законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителгән көннән башлап 10 көннән артык түгел;<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның барлык яки бер | 761 номерлы кагыйдәләрнең 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | өлешен электрон формада тапшырмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар булуы һәм (яки) аны түләү буенча килешү булмавы;<br>гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар формасында җибәрелгән очракта, аларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителгән көннән башлап ун көнлек чорда әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;<br>барлык документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителгән көннән башлап бер айдан артмаган чорда әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның барлык яки бер өлешен электрон рәвештә тапшырмау;<br>гариза бирүченең тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыруы;<br>электрон формада бирелгән документлардагы мәгълүматларның гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә күрсәтелгән документлардагы мәгълүматларга | |

| | | |
|---|---|---|
| | туры килмәве | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Әгәр әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, почта юлламасы белән яки электрон | 761 номерлы кагыйдәләрнең 13(1) п. |

| | | |
|---|---|---|
| турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | документ (документлар пакеты) рәвешендә җибәрелгән гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш вакыты тәмамлангач килсә, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала. Әгәр гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) ял яки бәйрәм көнендә алынса, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала. Субсидия бирү турында гариза бирү көне дип гариза бирүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык документлар тапшырылган көн санала Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла. Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә. | мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге. | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 п., Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта, аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.<br>Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү | |

| | | |
|---|---|---|
| | барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 һәм 3.1.3 пунктларны гамәлдән чыккан дип танырга;

3.3.1 пунктның алтынчы абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.3.3.1 пунктның өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.4.3.1 пунктның өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.5 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.6. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.2 пунктның беренче абзацында «(алга таба - Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)» сүзләрен «(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклый торган затның вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)»;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«(Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «Гариза бирүченең яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклаучы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләренә алмаштырырга;

«(гариза бирүченең имзасы)» сүзләрен «гариза бирүченең яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклаучы затның имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

| | | |
|---|---|---|
| аудит бүлегә башлыгы | | |

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүдәге чыгымнарга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 856 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 9 гыйнварындагы 8 номерлы, 2019 елның 7 маендагы 323 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүдәге чыгымнарга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гариза бирүчеләр – ялгыз яшәп эшләми торган, җитмеш һәм аннан да өлкәнрәк яшенә җиткән торак урын милекчеләре, шулай ук җитмеш һәм аннан да өлкәнрәк яшенә җитеп эшләми торган, 60 һәм 55 яшенә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) гражданнардан гына һәм эшләми торган I һәм (яки) II төркем инвалидларыннан торган гаилә составында яшәүче торак урын милекчеләре.»;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчада «2.8, 2.10, 2.11» саннарын «2.7, 2.9, 2.11» саннарына алмаштырырга;

1.5 пуктның бишенче абзацында «(алга таба – 601 номерлы указ)» сүзләрен «(алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).«;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләп торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләү чыгымнарына компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү. | РФ Торак кодексының 169 ст. 63-ТРЗ номерлы законның 8.3 ст. 1 п. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Нигезләмәнең 1.2 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә кабул ителә.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. | Нигезләмәнең 2.5 п. |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт | Компенсация бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче | Нигезләмәнең 2.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | кушымтасында китерелде;<br>аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгеләүче документларның күчермәләре;<br>компенсация алу хокукы булган гражданнарның гаилә әгъзаларына инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы документларның күчермәләре.<br>Үзәктә компенсация алу хокукы булган гражданнарның гаилә әгъзаларына инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы документ булган очракта, гариза бирүче күрсәтелгән документны тапшыру зарурлыгыннан азат ителә.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документны, банкта яки бүтән кредит учреждениесендә ачтырылган шәхси счет реквизитларын тапшыра (алуның аталган ысулын сайлаган очракта).<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану | |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхес таныклаучы документ күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:<br>гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәттә (алга таба – Росреестр);<br>мөрәҗәгать иткән айдан алда килгән соңгы 12 айда хезмәт эшчәнлегенең булмавы турында Россия Федерациясе Пенсия | Нигезләмәнең 2.4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | фондында булган белешмәләр;<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында).<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>3. Гариза бирүченең үзе яшәгән урынга карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Булган белешмәләр һәм документлар җыелмасы нигезендә дәүләт хезмәте алуга хокук булмавы ачыклану аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | Нигезләмәнең 2.6 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар), турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Кирәкле барлык документлары белән гариза килгән көнне.<br>Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә, яисә гариза Үзәк бүлегенә эш көне тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтәмле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>бүлек биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алу мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 п., 601 номерлы РФ Президенты указының пункты |

| | | |
|---|---|---|
| статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләренең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булуы;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| | (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 11 п.;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ ст.»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.1 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.5.1 пунктның өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.2 пунктның беренче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)» сүзләрен «(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклый торган затның вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)»;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 2 нче кушымтасын көчен югалткан дип танырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне
капиталь ремонтлауга кертем түләү
чыгымнарына компенсация билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(белешмәлек) кушымта

Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләү чыгымнарына компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затлар турында белешмәләр.

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |